УПРАВЛЕНИЕ ПО НАДЗОРУ ЗА ТЕХНИЧЕСКИМ СОСТОЯНИЕМ САМОХОДНЫХ МАШИН И ДРУГИХ ВИДОВ ТЕХНИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ҮЗЙӨРЕШЛЕ МАШИНАЛАР ҺӘМ БАШКА ТӨР ТЕХНИКАНЫҢ ТЕХНИК ТОРЫШЫНА КҮЗӘТЧЕЛЕК ИДАРӘСЕ

**ПРИКАЗ** | **БОЕРЫК**

18.05.2018 | Казан ш. | 01-05/139-пр

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигь булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законны, «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законны, Татарстан Республикасы Президентының «Аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигь булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-701 номерлы указын, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүче гражданнар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-702 номерлы указын үтәү максатында б о е р ы к  б и р ә м:

1. Кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигь булмаган балаларының керемнәре,

чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) расларга.

2. Вазыйфалар исемлегенә алар буенча түбәндәге вазыйфаи бурычларны үтәү күздә тотылган вазыйфалар кертелә дип билгеләргә:

хакимият вәкиле функцияләрен яисә оештыру-боеру яисә административ-хуҗалык функцияләрен даими рәвештә, вакытлыча яки махсус вәкаләтләр нигезендә гамәлгә ашыру;

гражданнарга һәм оешмаларга дәүләт хезмәтләре күрсәтү;

контроль һәм күзәтчелек чараларын гамәлгә ашыру;

бюджет ассигнованиеләрен бүлү турында карарлар әзерләү һәм кабул итү;

дәүләт мөлкәте белән идарә итү;

дәүләт сатып алуларын гамәлгә ашыру;

матди-техник ресурсларны саклау һәм бүлү.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы Үзйөрешле машиналарның һәм башка төр техниканың техник торышына күзәтчелек идарәсендә аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигълык яшенә җитмәгән балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга бурычлы булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 16 апрелендәге 01-05/57-пр номерлы;

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең 2015 елның 16 апрелендәге 01-05/57-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 10 декабрендәге 01-05/225-пр номерлы.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык                                                                 Р.Р. Зыятдинов

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең 2018 елның 18 маендагы 01-05/139-пр номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсендә аларны биләү коррупция куркынычларына бәйле булган, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, милеге һәм мөлкәти холыклы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе башлыгы – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең баш дәүләт инженер-инспекторы.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең төп вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе башлыгы урынбасары – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсе баш дәүләт инженер-инспекторы урынбасары.

3. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

районнардагы, шәһәрләрдәге бүлекләрнең башлыклары – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең баш дәүләт инженер-инспекторлары;

күзәтчелек һәм автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу бүлеге башлыгы – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең дәүләт инженер-инспекторы;

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең оештыру-хокук эше бүлеге башлыгы;

финанслау, бухгалтерия исәбенә алу һәм анализ бүлеге башлыгы – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең дәүләт инженер-инспекторы;

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең дәүләт хезмәте, кадрлар, эш башкару һәм хокукый тәэминат секторы мөдире.

4. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «белгечләр» категориясе вазыйфалары:

шәһәрләр һәм муниципаль районнар буенча Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең баш дәүләт инженер-инспекторлары консультант-урынбасарлары;

күзәтчелек һәм административ тәҗрибә секторының әйдәп баручы киңәшчесе – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең дәүләт инженер-инспекторы;

теркәү, автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу һәм махсус эш секторының әйдәп баручы киңәшчесе – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең дәүләт инженер-инспекторы;

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең матди-техник тәэминат секторы әйдәп баручы киңәшчесе.

5. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең әйдәп баручы вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең финанслау, бухгалтерия исәбенә алу һәм анализ бүлеге әйдәп баручы белгече.

6. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең өлкән вазыйфалар төркемендәге «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

теркәү, автоматлаштырылган рәвештә исәпкә алу һәм махсус эш секторының 1 разрядлы өлкән белгече – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең дәүләт инженер-инспекторы;

күзәтчелек һәм административ тәҗрибә секторының 1 разрядлы өлкән белгече – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең дәүләт инженер-инспекторы;

матди-техник тәэминат секторының 1 разрядлы өлкән белгече – Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең дәүләт инженер-инспекторы;

Татарстан Республикасы Дәүләт техник күзәтчелек идарәсенең финанслау, бухгалтерия исәбенә алу һәм анализ бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече.